КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 июль г.Казань № 634

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче; 2015 ел, 11 июнь, 433 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 684 нче; 2015 ел, 14 октябрь, 767 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 984 нче; 2016 ел, 31 март, 186 нчы; 2016 ел, 22 июль, 501 нче; 2017 ел, 8 май, 266 нчы; 2017 ел, 13 июнь, 375 нче; 2017 ел, 19 июнь, 390 нчы; 2017 ел, 31 август, 623 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 720 нче; 2018 ел, 15 февраль, 89 нчы; 2018 ел, 11 июнь, 448 нче; 2018 ел, 20 август, 675 нче; 2018 ел, 9 октябрь, 915 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1154 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1322 нче; 2019 ел,

27 февраль, 134 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 769 нчы; 2020 ел, 21 февраль, 127 нче; 2020 ел, 26 март, 219 нчы; 2020 ел, 22 апрель, 317 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 3.3.16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.3.16. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтләрне, шул исәптән түбәндәге юллар белән тормышка ашыра:

Татарстан Республикасының хезмәт базары торышы мониторингын үткәрү һәм аның фараз бәяләмәләрен эшләү, шулай ук һөнәрләрнең таләп ителүчәнлегенә анализ ясау;

Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләүне гамәлгә ашыру;

түбәндәгеләрне күзәтчелек итүне һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру:

тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә алуны;

инвалидларны эшсез буларак теркәүне;

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 7 статьясындагы 3 нче пунктының 11 нче пунктчасында каралган дәүләт гарантияләреннән тыш, халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүне;

яраклы эш эзләүдә ярдәм күрсәтү максатларында гражданнарны теркәү, шулай ук эшсез гражданнарны теркәү;

халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар нигезендә түбәндәге дәүләт хезмәтләре күрсәтү:

гражданнарга – яраклы эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү;

эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү;

эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү (башка җирлектә укуны кертеп);

түләүле иҗтимагый эшләр үткәрүне оештыру;

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны укудан буш булган вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү;

эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган, һөнәри уку үткән яки эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга аларны юридик зат, индивидуаль эшмәкәр йә крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) булышлык күрсәтү;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка урынга күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына һәм эшсез гражданнарга күченгәндә ярдәм күрсәтү;

инвалидларны эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәткәндә озатып йөрүне оештыру;

эшсез гражданнарны профильләштерү буенча махсус чаралар оештыру һәм үткәрү (эшсез гражданнарны аларның алдагы һөнәри эшчәнлеге юнәлешенә, белем дәрәҗәсенә, җенесенә, яшенә һәм башка социаль-демографик тасвирнамәләргә карап, хезмәт базарында барлыкка килә торган хәлне исәпкә алып, эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә аларга аеруча нәтиҗәле ярдәм күрсәтү максатларында төркемнәргә бүлү);

эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү өчен өстенлекле һөнәрләр (белгечлекләр) исемлеген билгеләү;

Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрын формалаштыру һәм алып бару;

халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар буенча ачыкланган бозуларның очракларын һәм сәбәпләрен бетерү һәм аның компетенциясе чикләрендә гражданнарның бозылган хокукларын торгызу буенча чаралар күрү;

өч яше җиткәнгә кадәр бала карау ялында булу чорында хатын-кызларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;

Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү;

вакансияләр һәм уку-укыту эш урыннары ярминкәләрен оештыру;

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга түбәндәге рәвешләрдә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру:

эшсезлек буенча пособиеләр;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку үтү һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында стипендия;

эшсезлек буенча пособие түләүнең билгеләнгән чоры бетүгә бәйле рәвештә, матди ярдәм күрсәтү;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри уку үтү һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында матди ярдәм;

картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнгә кадәр халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тәкъдиме белән билгеләнгән, шул исәптән вакытында алдан билгеләнә торган пенсия;

Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турындагы законнар нигезендә чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү турында һәм аларны файдалану хакында бәяләмәләр бирү;

хезмәт ресурсларының мобильлеген арттыру буенча төбәк программасын тормышка ашыру кысаларында эш бирүчеләргә хезмәт ресурсларын җәлеп итүдә булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнарны куллану, бозу сәбәпләрен анализлау тәҗрибәсен һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләүне гомумиләштерү;

инвалидларны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәткәндә озатып йөрүне оештыру чараларын халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү буенча дәүләт программасына кертү өчен тәкъдимнәр әзерләүдә катнашу;

инвалидларны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәткәндә озатып йөрү мәсьәләләре буенча эш бирүчеләрне мәгълүмат белән тәэмин итү;

инвалидларны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәткәндә озатып йөрүне оештыру максатларында федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү;

эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри уку үтү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында инвалидларга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән күздә тотылган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин